# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Лаеш муниципаль районы составына керүче "Габишев авыл җирлеге", "Никольский авыл җирлеге" һәм "Комлы Кавал авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Лаеш муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>**карта-схемасы**</u>




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
41 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *1(41) - 9(45)* | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| *9(45) - 35(56)* | - Питрәч муниципаль районы |
| *35(56) - 33(57)* | - Балык Бистәсе муниципаль районы |
| *33(57) - 51(32)* | - Алексеевск муниципаль районы |
| *51(32) - 50(33)* | - Спас муниципаль районы |
| *50(33) - 7(42)* | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| *7(42) - 1(41)* | - Югары Ослан муниципаль районы |

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Лаеш шәһәре |
| 2 | Александровка авыл җирлеге |
| 3 | Атабай авыл җирлеге |
| 4 | Олы Кабан авыл җирлеге |
| 5 | Габишев авыл җирлеге |
| 6 | Державино авыл җирлеге |
| 7 | Егорьево авыл җирлеге |
| 8 | Караеш авыл җирлеге |
| 9 | Хәерби авыл җирлеге |
| 10 | Көек авыл җирлеге |
| 11 | Макаровка авыл җирлеге |
| 12 | Кече Елга авыл җирлеге |
| 13 | Матюшино авыл җирлеге |
| 14 | Нармонка авыл җирлеге |
| 15 | Никольский авыл җирлеге |
| 16 | Орел авыл җирлеге |
| 17 | Пәрәү авыл җирлеге |
| 18 | Комлы Кавал авыл җирлеге |
| 19 | Рождествено авыл җирлеге |
| 20 | Сокуры авыл җирлеге |
| 21 | Урта Девятово авыл җирлеге |
| 22 | Столбище авыл җирлеге |
| 23 | Татар Сараланы авыл җирлеге |
| 24 | Татар Янтыгы авыл җирлеге |
| 25 | Чырпы авыл җирлеге"; |

2) 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта

**Лаеш муниципаль районының**
**"Габишев авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Габишев авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Габишев авыл җирлеге Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Лаеш муниципаль районының**
**"Габишев авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Габишев авыл җирлеге чиге Комлы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Габишев, Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комлы Кавал авылыннан 2,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып 2,73 км төньяк-көнбатышка таба "Казан — Боровое Матюшино" – Комлы Кавал – "Столбище – Атабай" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап, шуннан соң 455 м көньякка таба Комлы Кавал – Габишев автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталы буйлап 45 м көньяк-көнбатышка таба, 75 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 2,2 км көньякка таба, аннары 170 м көньяк-көнбатышка таба урман кварталы буйлап, 280 м шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 48 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 300 м өскә таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 160 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 750 м төньякка таба һәм төньяк чиге буйлап 1,05 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары шул ук юнәлештә 820 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Комлы Кавал – Орловка автомобиль юлына кадәр уза, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 405 м көньяк-көнчыгышка таба, 55 м көнчыгышка таба, 58 м

төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 385 м көньяк-көнчыгышка таба Комлы Кавал – Габишев автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, уртак юнәлештә 1,04 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап "Казан – Боровое Матюшино" – Комлы Кавал – "Столбище – Атабай" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, 720 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, аннары 1,9 км төньякка таба озын чокырның көнбатыш чиге буйлап Кавал күленә кадәр бара, 800 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге күлнең көнчыгыш чиге буйлап Габишев, Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комлы Кавал авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгыштагы Кавал күленең көнчыгыш ярында урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Габишев авыл җирлеге чиге Столбище авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньякка таба сазлыкка кадәр уза, шуннан соң сазлыкның көнбатыш кырые буйлап 850 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 30 м көньяк-көнбатышка таба һәм 1,2 км төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 300 м төньяк-көнбатыш юнәлештә сазлыкның көньяк кырые буйлап, аннары, тимер юл тармагын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 17 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Габишев," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Никольский авыл җирлеге чиге Комлы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никольский, Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Габишев авылыннан 4,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба, 800 м төньяк-көнбатышка таба, 750 м көньяк-көнбатышка таба, 460 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк чиге буйлап 2,2 км көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә 270 м шушы урманчылыктагы 69 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары шушы урман кварталы буйлап 60 м көньяк-көнбатышка таба уза, 85 м төньяк-көнбатышка таба һәм 439 м көньякка таба, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 110 м көньякка таба

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары шушы урманчылыктагы 68 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба, 170 м төньяк-көнбатышка таба, 70 м көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,48 км көньяк-көнчыгышка таба, 820 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 65 м көньяк-көнбатышка таба, автомобиль юлын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 340 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 940 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 40 м төньякка таба һәм төньяк чиге буйлап 1,0 км төньяк-көнбатышка таба Никольский, Орел һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Орел авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 20 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацтагы беренче һәм икенче җөмләләрдә "Комлы Кавал, Столбище авыл җирлекләре һәм Габишев авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Габишев, Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Комлы Кавал авыл җирлеге чиге Габишев авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып 2,73 км төньяк-көнбатышка таба "Казан – Боровое Матюшино" – Комлы Кавал – "Столбище – Атабай" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап, шуннан соң 455 м көньякка таба Комлы Кавал – Габишев автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталы буйлап 45 м көньяк-көнбатышка таба, 75 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 2,2 км көньякка таба, аннары 170 м көньяк-көнбатышка таба урман кварталы буйлап, 280 м шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 48 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 300 м өскә таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 160 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 750 м төньякка таба һәм төньяк чиге буйлап 1,05 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары шул ук юнәлештә 820 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Комлы Кавал – Орловка

автомобиль юлына кадәр уза, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 405 м көньяк-көнчыгышка таба, 55 м көнчыгышка таба, 58 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 385 м көньяк-көнчыгышка таба Комлы Кавал – Габишев автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, уртак юнәлештә 1,04 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап "Казан – Боровое Матюшино" – Комлы Кавал – "Столбище – Атабай" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, 720 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, аннары 1,9 км төньякка таба озын чокырның көнбатыш чиге буйлап Кавал күленә кадәр бара, 800 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге күлнең көнчыгыш чиге буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Комлы Кавал авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба, 800 м төньяк-көнбатышка таба, 750 м көньяк-көнбатышка таба, 460 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк чиге буйлап 2,2 км көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә 270 м шушы урманчылыктагы 69 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары шушы урман кварталы буйлап 60 м көньяк-көнбатышка таба уза, 85 м төньяк-көнбатышка таба һәм 439 м көньякка таба, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 110 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары шушы урманчылыктагы 68 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба, 170 м төньяк-көнбатышка таба, 70 м көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң бу урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,48 км көньяк-көнчыгышка таба, 820 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 65 м көньяк-көнбатышка таба, автомобиль юлын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 340 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 940 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 40 м төньякка таба һәм төньяк чиге буйлап 1,0 км төньяк-көнбатышка таба Никольский, Орел һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Орел авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

5) 24 нче кушымтада:

а) сигезенче абзацтагы беренче һәм икенче җөмләләрдә "Комлы Кавал, Столбище авыл җирлекләре һәм Габишев авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Габишев, Комлы Кавал һәм Столбище авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

б) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Столбище авыл җирлеге чиге Габишев авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньякка таба сазлыкка кадәр уза, шуннан соң сазлыкның көнбатыш кырые буйлап 850 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 30 м көньяк-көнбатышка таба һәм 1,2 км төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 300 м төньяк-көнбатыш юнәлештә сазлыкның көньяк кырые буйлап, тимер юл тармагын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.".

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты


ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 30-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Лаеш муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

район чиге

җирлекләрнең чикләре

торак пункт

I - Габишев авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Комлы Кавал авыл җирлеге территориясе

II – Комлы Кавал авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Никольский авыл җирлеге территориясе